# МОҢ БУЛЫП АГЫЛГАН ГОМЕР...

"Бөек батырлык- тарих түрендә" циклыннан музей дәресе

**З.М. Җиһаншина**,
музей җитәкчесе,
ТР Бөгелмә муниципаль районы МБГББУ
Кодаш төп гомуми белем бирү мәктәбе

**Максат:** Бөек Ватан сугышыннан исән-имин әйләнеп кайткан ветеран авылдашларыбыз турындагы материалларны туплауны дәвам итү.
Укучыларда авыл кешеләренең язмышларына, туган як тарихын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

**Укытучы:** Укучылар, без бүген чираттагы музей дәресенә җыелдык. Быел илебез тарихында зур урын алып торган вакыйга – Бөек Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итәчәкбез. 2015 ел - Россиядә һәм Татарстан Республикасында Әдәбият елы дип игълан ителде. Шул уңайдан "Бөек батырлык- тарих түрендә" циклын дәвам итеп, "Моң булып агылган гомер..." дигән темага шигырьләр иҗат иткән ветераннарыбыз турында сөйләшербез.

Бүгенге дәрестә сугыш ветераны Заһит абый Әхмәтшинның кызы Венера Заһит кызы Гаязова да катнаша. Шулай ук алдан әзерләнеп килгән " Минем авылым" туган якны өйрәнү түгәрәгенә йөрүче укучыларыбызның чыгышларын да тыңларбыз.

**1 нче укучы**. Эшне без шигырь язучы ветеран авылдашларыбызны эзләү, аларның иҗатларын тирәнтен өйрәнүдән башладык. Тикшеренү- эзләнү эшләре барышында музейдагы материалларны барладык, "Бөгелмә авазы", " Ватаным Татарстан" газеталары, "Кодашым- изге җирем " китабыннан, интернет ресурслардан файдаландык, ветеран-авылдашларыбызның гаилә архивлары белән таныштык, өлкән буын кешеләре белән очрашып, шигырь язган ике сугыш ветеранын эзләп таптык. (*1-3 нче слайдлар )*

**2 нче укучы.** 1990 елдан Бөгелмә шәһәренең Мактаулы гражданины булган, хәрби хезмәтен полковник дәрәҗәсендә тәмамлаган **Әхәт абый Галләмов** 1921 елда Кодаш авылында туа. Кечкенәдән сәләтле, өлгер егет, ун чакрым ераклыктагы күрше Карабаш мәктәбенә җәяү йөреп, урта белем ала. 1940 елның 9 сентябрендә 19 яшьлек Әхәт абый Кызыл Армия сафларына чакырыла. Бөек Ватан сугышы башланганчы, ул Маньчжурия чигендәге артиллерия полкында хезмәт итә. 1942 елның августында Иркутск шәһәрендәге Чернигов хәрби-инженер училищесын уңышлы тәмамлаган яшь лейтенантны Урал хәрби округының инженер-мина бригадасына билгелиләр. 8 ай хезмәт иткәннән соң, аны 3 нче Белорус фронтына җибәрәләр. Орша юнәлешендәге сугышларда, Смоленск, Березино, Борисов, Минск, Лида, Гродно шәһәрләрен азат итүдә катнашып, ул Көнчыгыш Пруссиягә кадәр барып җитә. Кёнигсберг өчен сугышларда каты яралана. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Әхәт абый Галләмов ике Кызыл Йолдыз ордены һәм ике тапкыр II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә. Ул 2005 елда 84 яшендә вафат була. *(4 нче слайд)*

**3 нче укучы.** Озын, катлаулы тормыш юлы узган Әхәт абыйның туган авылына, туган нигезенә булган җылы хисләре шигырь юлларында чагыла.

**Әхәт Галләмов. "Кодашым"**

"Кодаш" дисәм, күз алдымда
Гаҗәеп яшел таулар,
Елгасына сакчы сыман
Торучы биек ярлар.
Уйсу җирдә күкрәп үскән
Шул чаклы бөдрә таллар!
Таулар аша офыклардан
Чакыра алсу таңнар.
"Кодаш" дисәм, үргә менәм,
Таулар өстендә урман.

Урман эче печән, җиләк...
Бәрәкәт белән тулган.
Чыксам басу- кырларыңа,
Салкын чишмәләр күрәм.
Сусавымны басар өчен
Шул чишмәләргә киләм.
Авылым тора күз алдымда
Таудан карагач менеп.
Гел кайтып- күреп торсам да,
Һаман сагынам кебек.*( 5 нче слайд)*

**4 нче укучы**. Шигърияткә гашыйк икенче ветеранебыз - **Заһит Сарим улы Әхмәтшин**. 1928 нче елның 7 нче сентябрендә хәзерге Лениногорск районы Зәй-Каратай авылында туа. 1944 нче елны, авыл мәктәбенең 7 нче сыйныфын тәмамлагач, 16 яшьлек Заһит абый үзе теләп сугышка китә. 1945 нче елның сентябрь аена кадәр Суслонгерда хәрби хәзерлек узгач, аны 59 нчы укчы-миномет полкына танк пулемётына каршы атучы итеп япон сугышына җибәрәләр. Заһит абыйга, сугыш тәмамлангач та, 6 ел дәвамында армия сафларында хезмәт итәргә туры килә. Ул II дәрәҗә Ватан сугышы ордены,“ За победу над Японией” һәм Жуков медальләре белән бүләкләнә. *(6,7 нче слайдлар)* Хәрби хезмәтен тутырып кайткан 23 яшьлек егетне язмыш Кодаш авылы укытучысы Зәйнуллина Асия белән очраштыра. Ул гомере буена “Актүбәнефть” идарәсендә шофер булып эшли. Заһит авый Әхмәтшин 69 яшендә вафат була.

**5 нче укучы.** Үзе теләп сугышка киткән 16 яшьлек егетнең күргән михнәтләре, Туган илгә мәхәббәте, җиңүгә булган ышанычы күп санлы шигырь юлларына салынган. Аның сугышта һәлак булган дуслары һәм хәбәрсез югалган абыйсы хакында түккән күз яшьләре тамган ул шигырьләргә. *(8 нче слайд)*

Менә аның берсе.

**Сынатмады татар егетләре**
**Заһит Әхмәтшин**

Кырык бердә кара болыт кебек
Басып керде фашист илләргә.
Кичекмәстән без дә күтәрелдек,
Соры шинель салып иңнәргә.
Туган илнең аяз күк йөзендә
Бомбовозлар очты үкереп.
Соры шинель кигән солдат егет
Брустверга менде сикереп.

Сынатмады татар егетләре,
Батырларча утка керделәр.
Курку белмәс арысланнар кебек
Фашистларны тетеп йөрделәр
Истән чыгармагыз батырларны,
Даны китсен ерак илләргә.
Һәйкәл булсын сезгә шигъри сүзем,
Яуда үлгән батыр ирләргә. (9 нчы слайд)

**Укытучы:** Заһит абый Әхмәтшинның “ Яз җилләре хәбәр китерә”, “Кайтмадылар алар әйләнеп”, “Хәтердә саклана” һ.б. шигырьләре күңелдә аеруча матур хисләр калдыра. (Түгәрәккә йөрүчеләр ясаган альбом күрсәтелә).

Заһит абыйның “Бөгелмә авазы” газетасында басылып килгән шигырләре турында элеккеге мөхәррир Мәхтүм абый Мостафин болай ди: “Аның каләме үткен, хисләре көчле. Заһит ага, гомумән, шигъри җанлы, хатирәләргә бай”. *(12 нче слайд)*

**Укытучы:** Безнең бүгенге очрашуда Заһит абый Әхмәтшинның кызы Венера апагыз да катнаша.

- Венера Заһитовна! Без Заһит абыйның сугыш хатирәләрен сурәтләгән шигырьләре белән таныштык. Туган якка багышланганнары бармы? Берәрсен укыгыз әле.

**Укытучы:** Әтиегезнең шигырьләрен кадерләп саклаганыгызны беләбез. Кечкенә китап итеп чыгару уегыз юкмы?

**Укытучы:** - Укучылар! Кызганыч, безгә Бөек Җиңү китергән сугыш ветераннарының сафлары елдан-ел сирәгәя. Шуңа күрә алар турындагы һәр мәгълүматны бөртекләп җыярга, аларның тормышын, батырлыгын өйрәнергә кирәк. Шиһабетдин Мәрҗанинең “Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк” дигән хак сүзләрен онытмыйк. Халкыбыз тарихын, аның батырлыгын өйрәнсәк, милләт буларак сакланып калырбыз. Каһарманлыгы, чыдамлыгы, батырлыгы, бердәмлеге һәм киләчәккә илаһи ышаныч саклый алганнары өчен ветераннар каршында олы рәхмәт һәм ихтирам хисләре белән баш иябез.*(13 нче слайд)*